**Татарстан Республикасы Азнакай район Советы карары**

Азнакай шәһәре №384-55 2015 елның «25» августыннан

Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2012 елның 28 маендагы 154-21 номерлы карары (2014 елның 29 гыйнварындагы 289-40 номерлы, 2014 елның 12 августындагы 316-45 номерлы, 2015 елның 30 апрелендәге 361-52 номерлы карарлар редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасының «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Азнакай район Советы карары хакында

“Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында” 2015 елның 21 июлендәге 59 номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы “Азнакай муниципаль районы” муниципаль берәмлеге уставының 92, 93 статьяларына таянып,

Азнакай район Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2012 елның 28 маендагы 154-21 номерлы карары (2014 елның 29 гыйнварындагы 289-40 номерлы, 2014 елның 12 августындагы 316-45 номерлы, 2015 елның 30 апрелендәге 361-52 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасының «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Азнакай район Советы карары проектын хупларга.

2. Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2012 елның 28 маендагы 154-21 номерлы карары (2014 елның 29 гыйнварындагы 289-40 номерлы, 2014 елның 12 августындагы 316-45 номерлы, 2015 елның 30 апрелендәге 361-52 номерлы карар редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай район Советының «Азнакай муниципаль районы»

муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карары проекты буенча гавами тыңлаулар уздырырга.

3. Әлеге карарны веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru. һәм веб-адрес буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга:http://aznakayevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Азнакай район Советының Законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис М.З.Шәйдуллин

2015 елның «25» августыннан 384-55 номерлы
Татарстан Республикасы Азнакай район Советы карарына кушымта

1. Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2012 елның 28 маендагы 154-21 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына (2014 елның 29 гыйнварындагы 289-40 номерлы, 2014 елның 12 августындагы 316-45 номерлы, 2015 елның 30 апрелендәге 361-52 номерлы карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 7 статьяда:

1.1.1 өлештә:

- 15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15) муниципаль район территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым җыю), транспортировкалау, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү эшчәнлеген оештыруда катнашу;»

- 16 пунктта «, шул исәптән сатып алу юлы белән,» сүзләрен төшереп калдырырга;

- түбәндәге эчтәлекле 23.1 пункт өстәргә:

"23.1) муниципаль район милкендәге мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрен) саклап калу, алардан файдалану һәм аларны популярлаштыру, муниципаль район территориясендә урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын (тарих һәм мәдәният ядкарьләрен) саклау;";

- 30 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) муниципаль район территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, муниципаль районның рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;»;

1.1.2. 4 өлештә:

- 1 пунктта халыкны су белән тәэмин итү, су бүлеп бирү, “халыкны ягулык белән тәэмин итү” сүзләрен төшереп калдырырга;

- 2 пунктта «авыл җирлекләренең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге» сүзләрен төшереп калдырырга, «аларда» сүзләрен «авыл җирлекләренең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында» сүзләренә алмаштырырга;

- 6 һәм 11 пунктларны төшереп калдырырга;

- 13 пунктта «, шул исәптән сатып алу юлы белән,» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 16 статьяның 3 өлешендәге 4 пунктына «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2013 елның 06 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 13 статьясы нигезендә районны үзгәртеп кору өчен район халкының тавыш бирү юлы белән йә гражданнар җыеннарында белдерелгән ризалыгын алу таләп ителгән очраклардан тыш,» сүзләрен өстәргә. "

1.3. 19 статьяның 4 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Гражданнардан сорашып белешүне билгеләү һәм үткәрү тәртибе әлеге Устав һәм (яисә) район Советының норматив хокукый актлары белән билгеләнә.»;

1.4. 37 статьяның 2 өлешен «хәлиткеч тавыш хокукына ия. " сүзләрен өстәргә;

1.5. 40 статьяның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) әлеге Устав һәм район Советы карарлары белән билгеләнгән вәкаләтләре чикләрендә, район Советы эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча карарлар һәм күрсәтмәләр чыгара, шулай ук әлеге Устав компетенциясенә федераль законнар нигезендә кертелгән башка мәсьәләләр буенча карарлар һәм күрсәтмәләр чыгара;»;

1.6. 46 статьяның 1 өлешендәге 6 пунктын түбәндәге эчтәлекле алтынчы абзац өстәргә:

«- җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларына, район Советы депутатларына, муниципаль хезмәткәрләр һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренә һөнәри белем һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыра, мәгариф турында Россия Федерациясе законнарында һәм муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе

законнарында каралган тәртиптә муниципаль хезмәт өчен кадрлар әзерләүне оештыра. »;

1.7. 84 статьяның 2 өлешендә «аларны акчалата тотуга чыгымнар» сүзләрен «аларның хезмәте өчен түләү чыгымнары» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарның 1.1.1 пунктының икенче абзацы, 1.1.2 пунктының икенче-дүртенче абзацлары 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru. һәм веб-адрес буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Азнакай район Советының Законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис